**Муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениесе Кадыбаш уртагомумбелем бирү мәктәбе Әгерҗе муниципаль районы Татарстан Республикасы**

# “Мәктәп- милли мәгарифне үстерүдә ресурс үзәк. Милли мәгариф- әхлакый һәм тәрбия нигезе” проектын тормышка ашыру

**(Грант "Поддержка педагогических работников, осуществляющих преподавание на родном татарском языке«)**

# Проектның максаты:

- ФДББС шартларында Туган телдә белем һәм тәрбия алучы белем бирү оешмаларының ресурс үзәге  булган милли мәктәп оештыру һәм аның эшчәнлеген белем, әхлакый һәм рухи тәрбия нигезе буларак тормышка ашыру

**Проектның максатчан группасы:**

1.ТР Әгерҗе муниципаль районы МБГУ Кадыбаш урта гомуми белем бирү мәктәбе һәм район милли мәктәпләре (МБГУ Исәнбай урта гомуми белем бирү мәктәбе, МБГУ Салагыш урта гомуми белем бирү мәктәбе, Ләбиб Айтуганов исемендәге Девятерня төп мәктәбе, МБГУ Көчек урта гомуми белем бирү мәктәбе)укучылары, укытучылары, әти-әниләре
2. Өстәмә белем бирү педагоглары (ДДТ ДО  “Радуга талантов”)
***социаль партнерлар:*** район мәгариф бүлеге, өстәмә белем бирү, культура учреждениеләре

# 1. Белем бирү оешмаларының конкурентлыкка сәләтлелеген үстерү юнәлеше

Теманың актуальлеген билгеләү, проблемалар буенча эшнең төп этапларын эшкәртү, куелган сораулар буенча эш формаларын хәл итү максатыннан, район күләмендә милли мәгарифне үстерү буенча МБГУ Кадыбаш, Исәнбай, Салагыш, Тирсә, Көчек урта мәктәпләре һәм Ләбиб Айтуганов исемендәге Девятерня төп мәктәбе белән берлектә ресурс үзәк эшен планлаштырдык. Проблемалар чыгарылды һәм психологик-педагогик әдәбият өйрәнелде.



# 2. Белем бирү процессына алдынгы тәҗрибәне һәм технологияләрне кертү юнәлешендә

Ресурс үзәкнең ике теоретик семинары узды. Берсе- МБГУ Кадыбаш урта мәктәбе базасында "Татар теле һәм әдәбияты дәресләрен модельләштерүдә заманча педагогик технологияләр", ә икенчесе МБГУ Исәнбай мәктәбе базасында "Дәресләрдә инновацион технологияләр куллану- белем сыйфатын үстерүнең бер шарты.Укыту процессында дистанцион укытуны максатчан куллану" темаларына практик семинарлар үтте



# 1. Белем бирү оешмаларының конкурентлыкка сәләтлелеген үстерү юнәлеше

Ресурс үзәкнең сәләтле балалар белән эшне оештыру планы тәкъдим ителде. Сәләтле балаларны үстерү, бәйгеләргә йөртү, матди яктан үсендерүне дә грант исәбенә ресурс үзәк үз өстенә алды. Кадыбаш мәктәбенең Муниципаль тур олимпиадада призлы урын алган 10 укучы ресурс үзәкнең грант исәбенә акчалата премиясенә лаек булдылар.(1 урын алган укучылар: Габбасова Лиана, Салихова Азалия, Закиров Нурсолтан- 500 сум, ә призер булган Залилова Лиана, Каюмов Шамил, Рамазанов Айназ, Муллахметов Эльвир, Вахитова Гүзәл, Каюмов Марат, Закиров Рушан-300 әр йөз сум бүләккә ия булды.)



# "Көчле дә ул, бай да, ягымлы да"

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миннехановның 2020 елның 5 нче октябре УП- 653 нче Указы нигезендә 2021 нче ел - "Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы" дип игълан ителде. Мәктәбебездә елны ачу тантанасы "Көчле дә ул, бай да, ягымлы да" дигән әдәби - музыкаль чара белән башланып китте. Тантанада башлангыч сыйныф укучылары, "Каз канаты" театр түгәрәге әгъзалары күренекле татар шагыйрьләренең туган тел турында шигырьләрен, җырларын башкардылар, әсәрләрен сәхнәләштерделәр. Бәйрәм Габдулла Тукайның "Туган тел" җырын күмәк башкару белән тәмамланды



# . Белем бирү оешмаларының конкурентлыкка сәләтлелеген үстерү юнәлеше

Бу уку елында ресур үзәк карамагында 11 укучы туган тел һәм әдәбияттан республика олимпиадасында катнашып, шуның 10 сы призлы урынга лаек булды. Республикада 2 шәр фәннән дә призер булган МБГУ Исәнбай мәктәбенең 9 нчы класс укучысы Хабирова Р., 11 нче класс укучылары Мөэминова Г., Нәгыймова И, МБГУ Кадыбаш урта мәктәбенең 7 нче класс укучысы Салихова А., 10 нчы класс укучысы Габбасова Л. грант исәбенә махсус бүләк белән бүләкләнде.



## *Белем бирү оешмаларының конкурентлыкка сәләтлелеген үстерү юнәлеше*

Татар теле һәм әдәбияты буенча Халыкара олимпаидада Гран- при алган Исәнбай укучысы Мөэминова Г. проект кысасында ресурс үзәкнең акчалата премиясенә лаек булды.



# *Этномәдәни белем бирү проектларын тормышка ашыру*

Төбәкара Лазерев укуларында Габбасова Л, Рамазанов А, Салихова А төрле номинацияләрдә 1 дәрәҗәдәге дипломнар белән бүләкләнде. (Җитәкчесе - Расулева Э.Р.) «Йолдызлык» фестивале лауреатлары булдылар. Бу укучыларга да ресурс проектының бүләге бирелде.



# Этномәдәни белем бирү проектларын тормышка ашыру

Бөтенроссия "Илһам", "Кайрый каләм-2021" иҗат көчләренең бәйгесендә Габбасова Л,, Салихова А. 2,3 урыннарга лаек булдылар. Сәләтле укучылар бу юлы да ресурс үзәкнең махсус призына лаек булдылар (500 сум күләмендә).



# Этномәдәни белем бирү проектларын тормышка ашыру

Ләбиб Айтуганов исемендәге Девятерня төп мәктәбендә 18 нче "Көмеш каләм" фестивале 28.04 дә узды. Фестивальдә 5 номинация буенча көч сынаштылар. Һәр номинация буенча ресурс үзәк 6 балага "Өметле киләчәк" махсус призын тапшырды ( һәр балага 350 сум күләмендә).



# Шигъри марафон

- Январь- февраль айлары дәвамында район һәм республика укытучылары өчен туган тел турында шигырь сөйләп, «Шигъри марафон» игълан ителде. 18 укытучы марафонда катнашты һәм милли ресурсның Рәхмәт хатына лаек булды.

“Мәктәп- милли мәгарифне үстерүдә ресурс үзәк. Милли мәгариф- әхлакый һәм тәрбия нигезе” проектын тормышка ашыру барышы ВКОНТАКТЕ социаль челтәрендә яктыртып барылды

- http://vk.com/club201935691